**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2016 ел, 30 декабрь № 1070

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында мәктәп автобусларын нәтиҗәле файдалану чаралары турында» 2006 ел, 21 август, 400 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 29 ноябрь, 669 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктта:

«укучыларны» сүзен «белем алучыларны» сүзләренә алмаштырырга;

3 нче пунктта «белем бирү учреждениеләре укучыларын» сүзләрен «гомуми белем бирү оешмаларында белем алучыларны» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру турындагы нигезләмәдә:

исемендәге «укучыларны» сүзен «белем алучыларны» сүзләренә алмаштырырга;

1 нче пунктта «белем бирү учреждениеләрендә укучыларны һәм тәрбияләнүчеләрне (алга таба – укучылар)» сүзләрен «гомуми белем бирү оешмаларында белем алучыларны (алга таба – белем алучылар)» сүзләренә алмаштырырга;

2 нче пунктта:

беренче абзацта «укучыларны» сүзен «белем алучыларны» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Автобус 1999 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертелгән ГОСТ Р 51160-98 «Балалар йөртү өчен автобуслар. Техник таләпләр» таләпләренә, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балалар төркемнәрен оешкан рәвештә автобуста йөртү

кагыйдәләрен раслау турында» 2013 ел, 17 декабрь, 1177 нче карары белән расланган таләпләргә җавап бирергә тиеш.»;

3 нче пунктта:

«укучыларны» сүзен «белем алучыларны» сүзләренә алмаштырырга;

«Татарстан Республикасының ЭЭМ ЮХИДИ» сүзләрен «Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ ЮХИДИ» сүзләренә алмаштырырга;

4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

автобусның хәрәкәт итү маршрутларын һәм графигын эшләргә һәм ел саен тәгаенләргә;

гомуми белем бирү оешмасы тәкъдиме буенча белем алучыларның дәрестән тыш вакытта автобуста чыгу графикларын эшләргә;

ЮХИДИ белән килештереп, белем алучыларны утырту һәм төшерү пунктларын билгеләргә;

балаларны өлкәннәр озата баруны тәэмин итәргә;

гамәлдәге норматив актлар һәм юл хәрәкәте иминлеге таләпләре нигезендә белем алучыларны йөртүне һәм мәктәп автобусларын эксплуатацияләүне тәэмин итәргә;

ЮХИДИ һәм юл оешмаларын җәлеп итеп, хәрәкәт итү маршрутларында автомобиль юлларына, белем алучыларны утырту һәм төшерү пунктларына комиссия тикшерүе үткәрергә.»;

6 нчы пунктта:

«укучыларны» сүзен «белем алучыларны» сүзләренә алмаштырырга;

тиешле килешләрдәге «белем бирү учреждениеләре» сүзләрен тиешле килешләрдәге «гомуми белем бирү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Белем алучыларны йөртүне гамәлгә ашыручы автобуслар белән идарә итү түбәндәге таләпләргә туры килгән йөртүчеләргә рөхсәт ителә:

соңгы өч календарь елда кимендә бер ел «D» категорияле транспорт чарасын йөртүче сыйфатында эш тәҗрибәсе булган;

соңгы ел эчендә транспорт чарасы белән идарә итү хокукыннан мәхрүм итү рәвешендә административ җәза яки административ кулга алу күздә тотылган юл хәрәкәте өлкәсендәге административ хокук бозулар кылмаган;

Россия Федерациясе Транспорт министрлыгы раслаган Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртү һәм йөкләр ташу куркынычсызлыгын тәэмин итү кагыйдәләре нигезендә балаларны йөртү куркынычсызлыгы буенча рейс алдыннан инструктаж үткән;

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә рейс алдыннан медицина тикшерүе үткән.»;

7 нче пунктта «Белем бирү учреждениеләрендә укучылар, тәрбияләнүчеләр» сүзләрен «Гомуми белем бирү оешмаларында белем алучылар» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәктәп автобус маршрутын ачу турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2010 ел, 3 август, 615 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 20 октябрь, 831 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуладагы «укучыларны» сүзен «белем алучыларны» сүзләренә алмаштырырга;

2 нче пунктта:

«укучыларны» сүзен «белем алучыларны» сүзләренә алмаштырырга;

«гомуми белем бирү учреждениеләре» сүзләрен «гомуми белем бирү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Мәктәп автобус маршрутын ачу турындагы нигезләмәдә:

1.2 нче пунктта «Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 1997 елның 8 гыйнварындагы 2 нче боерыгы белән расланган Пассажирларны йөртү куркынычсызлыгын тәэмин итү турындагы нигезләмә (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында 1997 елның 14 маенда 1302 нче теркәлгән) һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3 нче пунктның бишенче абзацында «укучыларны» сүзен «белем алучыларны» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 нче пунктта:

«гомуми белем бирү учреждениеләре» сүзләрен «гомуми белем бирү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

«гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын» сүзләрен «гомуми белем бирү оешмаларында белем алучыларны» сүзләренә алмаштырырга;

2.5 нче пунктта «Актлар ачыкланган бозуларны бетерүгә вәкаләтле оешмаларга бирелергә тиеш» сүзләрен «Актлар ачыкланган бозуларны бетерүгә вәкаләтле оешмаларга, шулай ук Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына бирелергә тиеш» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков